БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

9 август 2023 ел № 204

**Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2016 елның 23 декабрендәге 68 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 3 февралендәге 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2016 елның 23 декабрендәге 68 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2017 елның 24 июнендәге 88 номерлы, 2018елның 1 ноябрендәге 151 номерлы, 2020 елның 9 октябрендәге 10 номерлы, 2022 елның 18 январендәге 100 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге 186 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Муниципаль хезмәт Балтач район Советында, Балтач район башкарма комитетында һәм Балтач муниципаль районының башка җирле үзидарә органнарында (алга таба - җирле үзидарә органнары) штат вазыйфаларында гамәлгә ашырыла.»;

2) 7 статьяның 7.8 пунктында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

3) 9 статьяның 9.2 пунктында « ,Балтач муниципаль районы сайлау комиссияләренең» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 11 статьяның икенче абзацында « ,муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 12 статьяда:

12.5 пунктта «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

12.7 пунктта «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

12.8 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 14 статьяда:

14.6 пунктта «дөрес булмаган яисә» сүзләрен төшереп калдырырга, «федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 14.7 пунктны өстәргә:

«14.7. Муниципаль хезмәткәрнең әлеге статьяның 14.6 пунктында күрсәтелгәнчә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыруы муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

7) 15 статьяның 15.2 пунктында «әлеге нигезләмәнең 15.1 пунктында» сүзләрен «әлеге Нигезләмәнең 15 статьясының 15.1 пунктында» сүзләренә алмаштырырга;

8) 17 статьяның 17.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17.3. Җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә җирле үзидарә органнары арасында төзелгән кадрлар эше буенча аерым функцияләр тапшыру турындагы килешүләр нигезендә конкурс уздыру буенча Бердәм конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә.»;

9) 18 статьяга түбәндәге эчтәлекле 18.7 пункт өстәргә:

«18.7. Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен аттестацияләү Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының бердәм аттестация комиссиясе тарафыннан җирле үзидарә органнары арасында төзелгән кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешүләр нигезендә уздырыла.»;

10) 23 статьяга түбәндәге эчтәлекле 23.3 пункт өстәргә:

«23.3. Җирле үзидарә органы бетерелүгә яисә җирле үзидарә органы хезмәткәрләре штаты кыскаруга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрләр белән хезмәт килешүе өзелгәндә, муниципаль хезмәткәргә, оешма бетерелүгә йә оешма хезмәткәрләре штаты кыскартылуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән очракта, хезмәткәрләр өчен хезмәт законнарында билгеләнгән гарантияләр бирелә.»;

11) 24 статьяга түбәндәге эчтәлекле 24.4 пункт өстәргә:

«24.4. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән затның салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмаганда башкарыла.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү турында мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә әлеге бурыч капланган очракта,тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү мондый билгеләнеш өчен мөрәҗәгать иткән көннән башлап гамәлгә ашырыла.»;

12) 28 статьяга түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Мондый чикләүләрне, тыюларны үтәмәү,мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәү һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон һәм башка федераль законнар белән коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәү,шулай ук мондый бурычларны үтәмәү «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль законның 13 статьясының 3-6 нче өлешләрендә каралган тәртиптә аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе буларак танылган очракта, муниципаль хезмәткәр җаваплылыктан азат ителә».»;

13) 29 статьяның бишенче абзацында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин